КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 16 март г.Казань № 220

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һөнәри белем бирү оешмала-рында урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программалары буенча күпбалалы гаиләләрдән балаларны укыту кыйммәтен компенсацияләү турында» 2025 ел, 6 октябрь, 793 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һөнәри белем бирү оешмаларында урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программалары буенча күпбалалы гаиләләрдән балаларны укыту кыйммәте өчен, алар көндезге бүлектә белем алу шарты белән, 30 процент күләмендә компенсация бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һөнәри белем бирү оешмала-рында урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программалары буенча күпбалалы гаиләләрдән балаларны укыту кыйммәтен компенсацияләү турында» 2025 ел, 06 октябрь, 793 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һөнәри белем бирү оешмаларында урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программалары буенча күпбалалы гаиләләрдән балаларны укыту кыйммәте өчен, алар көндезге бүлектә белем алу шарты белән, 30 процент күләмендә компенсация бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Компенсация алу хокукы түбәндәге категория гражданнарга (алга таба – гариза бирүчеләр) бирелә:

23 яшькә кадәр булган, күп балалы гаилә әгъзасы булган, һөнәри белем бирү оешмасы белән килешү төзегән балигъ булган укучыга;

күп балалы гаилә әгъзасы булган, 23 яшькә кадәр булган, әлеге күп балалы гаилә әгъзасы булган укучыга карата һөнәри белем бирү оешмасы белән килешү төзегән ата-ананың (уллыкка (кызлыкка) алучының) берсенә;

күп балалы гаилә әгъзасы булган, 14 яшьтән 18 яшькә кадәр булган, әлеге күп балалы гаилә әгъзасы булган һәм законлы вәкиленең язма ризалыгы белән һөнәри белем бирү оешмасы белән килешү төзегән балигъ булмаган укучының ата-анасының (уллыкка (кызлыкка) алучының) берсенә.

Әлеге Нигезләмәне куллану максатларында күпбалалы гаилә дигәндә гаилә составында өч һәм аннан күбрәк, олы баласына 18 яшь яки белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге бүлектә белем алу шарты белән 23 яшь тулганга кадәр балалары (тәрбиягә алган балаларны кертеп) булган, аларда гаиләнең барлык әгъзалары Россия Федерациясе гражданнары булган гаилә аңлашыла.

Белем бирү хезмәтләре өчен фактта түләү гариза бирүченең гаилә әгъзасы тарафыннан башкарыла.

Гариза бирүче исеменнән гамәлдәге законнар белән билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамәдә вәкаләтләре билгеләнгән затлар (алга таба – гариза бирүченең вәкаләтле вәкиле) булырга мөмкин.»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Компенсация 2025 елның 1 сентябреннән башлап уку чорлары өчен фактик түләнгән уку бәясенең 30 проценты күләмендә бирелә.»;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Компенсация билгеләү өчен гариза бирүче яки гариза бирүченең вәкаләтле вәкиле Үзәк бүлегенә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча, гариза бирүченең банкта яки башка Россия кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитларын күрсәтеп, ткомпенсация билгеләү турында гариза (алга таба – гариза) тапшыра, аңа түбәндәгеләрне терки:

чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән бала туу турында таныклык күчермәләре, баланың Россия Федерациясе гражданлыгы булуын раслый торган тамга куелган һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсе;

чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән никахлашуны теркәү турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсенең күчермәсе;

чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән бала туу турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсенең күчермәсе;

һөнәри белем бирү оешмасында көндезге уку формасы буенча түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү турында шартнамә күчермәсе;

гариза бирүче яки аның гаилә әгъзасы тарафыннан башкарылган, һөнәри белем бирү оешмасында укуның тиешле чоры өчен фактта түләүне раслый торган документлар күчермәләре;

баланың һөнәри белем бирү оешмасында көндезге уку формасы буенча уку фактын раслый торган документ күчермәсе;

Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү фактын билгеләү турында суд карарының закон көченә кергән күчермәләре – Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлмәгәндә;

гариза бирүченең вәкаләтле вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, ышанычнамә күчермәсе.

Документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнары нигезендә расланмаган очракта, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан таныклана.

Гариза почта аша җибәрелгәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланган булырга тиеш.

Гариза бирүче яки гариза бирүченең вәкаләтле вәкиле Үзәк бүлегенә мөрәҗәгать иткәндә шәхесне раслый торган документын күрсәтә.»;

10 пунктның икенче абзацында «өченче һәм дүртенче абзацларда» сүзләрен «алтынчы һәм җиденче абзацларда» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктның тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе территориясендә Россия Федерациясе гражданинының шәхесен раслаучы документ турында.»

13 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гариза биргән датага мөрәҗәгать итүченең әлеге Нигезләмәнең 2 пунктындагы бишенче абзацында билгеләнгән гаилә составына карата таләпләрне үтәмәү;»;

унынчы абзацта «өченче һәм дүртенче абзацларда» сүзләрен «алтынчы һәм җиденче абзацларда» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«мөрәҗәгать итүченең гаилә составы әлеге Нигезләмәнең 2 пунктындагы бишенче абзацында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве.»;

15 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Компенсация бирү әлеге Нигезләмәнең 13 пунктының унынчы - ундүртенче абзацларында күрсәтелгән хәлләр барлыкка килү турында Үзәк бүлегенә мәгълүм булган айдан соң килүче айдан туктатыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин